# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

26.09.2016 № 12/2

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «җирле референдум турында»2004 елның 25 мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 статьялары, Иштирәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2016 елның 20 ноябренә якшәмбе көнне Иштирәк авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Иштирәк авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итәргә.

«2016 елда яшәү урыны буенча Иштирәк авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 200 (ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 100 (йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын тоту:

- Күктәк Мирсәет авылында материаллар сатып алу һәм зират коймасы урнаштыру -14 800 сум;

- Бай Бүләк авылында материаллар сатып алу һәм зират коймаларын урнаштыру-15 500 сум.

2) җирлек чикләрендә су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу:

- Яңа Бүләк авылында чишмәне төзекләндерү - 44 500 сум;

- Иске Теләнче авылында чишмәне төзекләндерү - 12 500 сум.

3. Референдумны әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссияләренә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрүгә бәйле чыгымнарны Иштирәк авыл җирлеге бюджеты хисабына тормышка ашырырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» «Светлый путь») газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырып халыкка җиткерергә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе М.С. Сагетдинов